# Яңа буын драматургы

Мең еллык татар әдәбияты тарихын күзаллаганда шуңа игътибар итәсең: безнең бары тик драма жанрында гына эшләүче хатын-кызларыбыз юк икән! Дөрес, бу очракта беренче татар драма әсәренең XIX гасыр ахырында гына язылуын, гүзәл затларыбызның XX йөз башында гына кулларына каләм алып әдәби әсәрләр иҗат итә башлавын исәпкә алырга кирәк. Дөрес, ир-ат драматургларыбыз шактый, ләкин ике җенеснең дә тигезлеге, балансны саклау кирәклеге турында фикер йөрткәндә, уйга каласың. Күңелдә сорау арты сорау уяна. Нигә юк? Кайчан булыр? Сәбәп һәм хикмәт нәрсәдә?..

Уйларым яшь драматург Раилә Мөхсинова кандидатурасына тукталгач, күңелгә җылы йөгерде.

Раилә мәктәп яшеннән үк шигырьләр, мәкаләләр язып, республика матбугаты белән актив элемтәдә торды. Казан дәүләт университетының татар филологиясе һәм тарихы факультетына укырга кергәч, «Әллүки» әдәби-иҗат берләшмәсе тормышының үзәгендә кайный башлагач, игътибарын драма жанрына юнәлтте. Студент елларында Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры оештырган махсус укуларга йөрүе, Туфан Миңнуллин, Мансур Гыйләҗев кебек күренекле драматурглардан дәресләр алуы, 2004 елда «Яңа татар пьесасы» конкурсында беренче язылган «Кайнар токмачлы аш» әсәре белән лауреат исеменә лаек булуы аңа канат куйды. Раилә бер-бер артлы сәхнә әсәрләре иҗат итәргә тотынды. Һәм менә — беренче китап. Комедияләр һәм драмалар.

Алар авыл һәм район халык театрлары тарафыннан куелды. Г. Камал театрының кече сәхнәсендә диплом спектакльләре буларак тәкъдим ителде, күмәк җыентыкларда басылып чыкты. Кыскасы, апробацияне, ягъни беренче иң катлаулы сынауны узды.

Арада иң популяры, иң еш куелганы, әлбәттә, «Кайнар токмачлы аш» комедиясе. Ул 2011 елда Баулы халык театры тарафыннан сәхнәләштерелә. (Режиссёры — Миргалиян Фәхриев.) Халык театрларының «Идел-йорт» дип аталган XI Республика фестивалендә

күрсәтелә. Әсәр шулай ук Лаеш, Балык Бистәсе, Апас, Арча районы яшьләре тарафыннан да куела. Комедиянең популярлыгы — авторның бүгенге көн яшьләре, студентлар тормышын сурәтләвендә. Ә кем яшьлекне яратмый да аңа сокланмый ди?..

Китапка кергән «Күрәзәче» Зөлфирә» комедиясендә ялган, җиңел юл белән акча эшләү фаш ителсә, «Йорт иясе»ндә татар авылының юкка чыга баруы һәм моның төп сәбәпчесе авыл кешеләре үзләре икәнлеге ачып салына. «Тәмуг газабы» драмасы катнаш никах проблемасын, бүгенге көндә ислам диненең кешелек тормышындагы ролен чагылдыра, «Яшьлек хатасы»нда яратмыйча гаилә кору, дусларга, якыннарга кешелекле мөнәсәбәт мәсьәләләре яктыртыла.

Күптән түгел Раилә Мөхсинованың үз заманының күренекле драматургы, «Сине ташлап китә алмыйм», «Кыз бирү» комедияләре, «Тормыш бусагасында», «Тол хатыннар, тол кызлар», «Уракчы кыз» драмалары, «Зөһрә йолдыз» трагедиясе авторы Сәет Шәкүровның якын туганы булуы ачыкланды. Бу вакыйга — авторның үзе өчен дә зур яңалык. Димәк, талант һәм тырышлык янына нәселдәнлек күрсәткече булган геннар да килеп кушылса, бу каләм иясеннән киләчәктә күпне көтәргә мөмкин дигән сүз.

Яңа буын драматургы булып өлгергән Раилә Мөхсинова әсәрләрен зур сәхнәләрдә дә күрербез, премьераларга йөрербез әле без, Алла боерса!

Ленар Шәех,<br>филология фәннәре кандидаты

# Кайнар токмачлы аш

*Комедия*

Катнашалар:

Илгиз — тиз кызып китүчән, мактанчык.
Айдар — сабыр холыклы, тыныч.
Марат — «заучка».
Алсу — чекерәеп тора торган «боевой» кыз.
Гөлназ — үзен генә уйлый торган замана кызы.
Гөлфинә — хаклык, дөреслек өчен көрәшүче.

Барысы да тулай торакта яшәүче бишенче курс студентлары.

## Беренче күренеш

Тулай торак. Егетләр бүлмәсе. Бүлмә җыештырылмаган. Сәхнә уртасында «Щи» дип язылган зур кәстрүл тора, әлеге кәстрүл чүп-чар савыты ролен үти.

Катнашучылар барысы бергә җырлыйлар.

Шаян студентлар без,
Бүгенге һәм кичәге.
Белем туплап яшәүчеләр,
Милләтнең киләчәге.

Кушымта:

Студент булуы рәхәт,
Шатлыклы һәм күңелле.
Зачёт, семинарлары
Куркытса да күңелне.

Студент ул кытай телен
Бер төндә дә өйрәнә.
Сессиядә укый-укый,
Йөрәкләр өзгәләнә.

Кушымта.

Саташтыра төннәр буе
Имтихан сораулары:
Нинди билет эләгер дип
Куркыта торганнары.

К у ш ы м т а.

Тулай торакта җыелып
Шаярабыз, көләбез.
Әгәр кунакка дәшсәгез,
Җыелышып киләбез.

Таралышалар. Бүлмәгә, бәхәсләшә-бәхәсләшә, А й д а р белән И л г и з кайтып керә.

А й д а р *(кулларын селкеп).* Күпме әйтеп киләм мин үзеңә, һаман тыңламыйсың. Кермә, дидем бит инде шул укытучыга. Болай гына зачётыңны бирә алмыйсың, барыбер куймый.

И л г и з. Нишләп әле бирә алмыйм ди?! Бүген бирә алмадым, шуннан ни?

А й д а р. Ул бит яшь укытучы, сорауларны да күп бирә, ичмасам, укып та карамыйсыз бит.

И л г и з. Яшь кыз булгач, тем более шәп! Ничек кенә әйләндерәм әле мин аның башын. Әй, хатын-кыз укытучыга зачёт бирү бернәрсә түгел лә ул.

А й д а р. Әнә Мараттан үрнәк ал! Укый, тырмаша, кызыл дипломга бара. Ә син аның ярдәменнән башка хәтта шпаргалка да яза белмисең.

И л г и з *(кулына тотып алып кергән сумкаларын караватка атып бәрә).* Йә, җитте инде, синең шул һаман акыл өйрәтү булыр. Туйдым, юл буе шушы зур сумкаларны күтәреп кайттым, бөкрәям дип торам. Син тагын нервада уйныйсың.

А й д а р. Ярый соң, тынычлан. Әз генә әйтергә ярамый, бүртенә башлыйсың. *(Сумкадагы китапларга карап.)* Нәрсә, Марат тагын китаплар алганмыни?

И л г и з. Кем алсын, мин түгел бит инде. Шулкадәрле укысаммы, башымда бер генә бөртек тә чәч калмас иде, мөгаен. Атна саен сумка тутырып китап ташый, ничек укып бетерәдер, күзе дә чыкмый үзенең.

А й д а р. Йә, йә, бүлмәдәшеңне яманлап торма әле, үзеңне бел!

Илгиз. Беләм мин үземнең кем икәнемне, кстати, син тоже не подарок!

Айдар. Нәрсә?

Илгиз. Шаяртам инде, мин бит Маратны да яманларга теләмим. Укысын, башы исән чакта. Аның әле миңа диплом да язып бирәсе бар. Но кайбер моментларда шул укуы башка каба, бесит!

Айдар. Булды, Илгиз, зачётыңны уйла, гайбәт сатып торганчы.

Илгиз. Институтта гына җитмәгән, өйгә кайткач ял итим инде.

Айдар. Менә ничек икән?! Ял кирәк аңа, ял ит соң, кем мешать итә сиңа? *(Өстәл янына килеп, кәстрүлне ачып-ачып карый. Борынын җыерып.)* Фу, әчегән... Нәрсә ашарбыз икән бүген?! Что-то тәмле аш ашыйсы килә. *(Хыялга бирелеп.)* Карале, Илгиз, ә син нинди аш яратасың ул?

Илгиз *(караватка ятып, корсагын ышкый).* Ашмы?.. О-о, теге өченче көнне ашадык ич әле кайнар токмачлы тавык шулпасын... Вәт ошаган иде ул миңа... Бәрәңгеләре дә изрәп, сытылып торалар иде...

Айдар. Бүген нишләрбез икән?..

Илгиз. Вәт сорау, ничек инде нишләрбез, ашарбыз, конечно, общагада тамак ачамыни ул?

Айдар. Пешерәсе дә килми. Әй, Марат кайткач уйлашырбыз әле.

Илгиз. Нигә Маратны көтәргә, ул бит безнең «белем короле». Без аңа кайтырына ук берәр нәрсә булса да әзерләп куярга тиеш.

Айдар. Ничек инде әзерләп? Әллә, прогресс ясап, аш пешермәкче буласыңмы?

Илгиз. Пешергән ди Илгиз, мин пешерсәм, кызыл кар явар, кыш көне яшен яшьнәр.

Айдар. Ә нишләмәкче буласың?

Илгиз. Хәзер, сабыр ит, иптәш, мин дә уйлап тапмасаммы?! Мин дә сезне ашатмасаммы! Хәзер киләм, сабыр ит. *(Чыгып китә.)*

Айдар *(үз-үзенә).* Тагын ниләр генә майтара икән инде, Ходаем? Тагын берәр мөгез чыгармаса гына ярый да бит. Әй, теләсә нишләсен, үз акылы үзендәдер әле. Газетадагы сконвордларны чишеп алыйм, ял да итәрмен бераз. Чү, кая соң әле газета-